СОВЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**
**КАРАРЫ**

**16 октябрь 2020 ел** **№ 13**

**Арча район Советының 2017 елның 27 сентябрендәге 142 номерлы «Арча муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан түләүсез нигездә бердәм башкарма орган буларак коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашуга (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы белән идарә итүдә, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында (конференция) катнашудан тыш) яисә аларның коллегиаль органнары составына керүгә яллаучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында" карарына үзгәрешләр кертү турында (19.06.2019, №255, 11.03.2020, № 312 үзгәрешләр белән)**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законга туры китерү максатыннан Арча район Советы **карар бирде**:

1. Арча район Советының 2017 елның 27 сентябрендәге 142 номерлы «Арча муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан түләүсез нигездә бердәм башкарма орган буларак коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашуга (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы белән идарә итүдә, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында (конференция) катнашудан тыш) яисә аларның коллегиаль органнары составына керүгә яллаучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында" карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Арча район Советының 2017 елның 27 сентябрендәге 142 номерлы карарына кушымтаның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: “Арча муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан түләүсез нигездә

коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу өчен яллаучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турында Нигезләмә".

1.2. Арча район Советының 2017 елның 27 сентябрендәге 142 номерлы «Арча муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан түләүсез нигездә бердәм башкарма орган буларак коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашуга (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы белән идарә итүдә, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында (конференция) катнашудан тыш) яисә аларның коллегиаль органнары составына керүгә яллаучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турында Нигезләмәне кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4 Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районы рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә (http://arsk.tatarstan.ru).

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Арча район Советының законлылык, җәмәгать тәртибен саклау һәм җирле үзидарә буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
район Советы рәисе И.Г. Нуриев

Арча район Советының
16 октябрь 2020 ел, №13
карарына кушымта

**Арча муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан түләүсез нигездә коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу өчен яллаучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турында**
**Нигезләмә**

1. Әлеге Арча муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан түләүсез нигездә бердәм башкарма орган буларак коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашуга (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы белән идарә итүдә, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында (конференция) катнашудан тыш) яисә аларның коллегиаль органнары составына керүгә яллаучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турында Нигезләмә «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 3 пункты нигезендә эшләнде.

2. Муниципаль хезмәткәрләрнең коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашуы мәнфәгатьләр каршылыгына яки мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү мөмкинлегенә китерергә тиеш түгел.

3. Муниципаль хезмәткәрнең коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу турында рөхсәте (алга таба – гариза) Арча муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе яки Арча муниципаль районы башлыгы, «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУ җитәкчесе (алга таба - җирле үзидарә органы җитәкчесе) исеменә әлеге Нигезләмәнең 1 нче кушымтасы буенча язма рәвештә төзелә.

4. Муниципаль хезмәткәрләр коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә планлаштырылган катнашканчыга кадәр кадрлар эшен алып бару буенча вазыйфалар йөкләнгән затка гариза тапшыралар.

5. Гариза муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан түләүсез нигездә бердәм башкарма орган буларак коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә катнашуга (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы белән идарә итүдә, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының, күчемсез милек милекчеләр ширкәтенең гомуми җыелышында (конференция) катнашудан тыш) яисә аларның коллегиаль органнары составына керүгә яллаучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алуга гаризаларны теркәү

журналында гариза кергән көнне кадрлар эшен алып бару бурычы йөкләнгән зат тарафыннан теркәлә. Теркәү журналы битләре җирле үзидарә органы мөһере белән расланган, номер сугылган һәм беркетелгән булырга тиеш.

6. Теркәү турында тамга куелган гариза күчермәсе, гаризаны теркәү номеры, гаризаны теркәгән кадрлар хезмәте затының фамилиясен, инициалларын һәм вазыйфасын күрсәтеп, муниципаль хезмәткәргә аның гаризаларны теркәү журналында имзасын куйдырып бирелә.

7. Кадрлар эшен алып бару вазыйфалары йөкләнгән зат гаризаны алдан карап тикшерүне һәм аңа муниципаль хезмәткәрнең коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу мөмкинлеге яисә мөмкин булмавы турында дәлилләнгән бәяләмә әзерләүне гамәлгә ашыра (алга таба - дәлилләнгән бәяләмә). Дәлилләнгән бәяләмәне әзерләгәндә, муниципаль хезмәткәр ризалыгы белән кадрлар эшен алып бару вазыйфалары йөкләнгән зат аның белән әңгәмә үткәрә һәм язма аңлатмалар ала.

8. Дәлилләнгән бәяләмәдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) коммерцияле булмаган оешмага карата кадрлар, оештыру-техник, финанс, матди-техник яки башка мәсьәләләр буенча карарлар кабул итү буенча муниципаль хезмәткәрнең вәкаләтләрен, шул исәптән әлеге коммерциячел булмаган оешма тарафыннан билгеле бер эшчәнлек төрен һәм (яисә) аерым гамәлләрне гамәлгә ашыруга рөхсәт бирү белән бәйле карарлар кабул итү буенча муниципаль хезмәткәрнең вәкаләтләрен анализлау;

2) муниципаль хезмәткәрнең коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу очрагында мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү мөмкинлеген анализлау.

9. Муниципаль хезмәткәр гаризасы һәм дәлилләнгән бәяләмә кадрлар эше алып бару вазыйфалары йөкләнгән зат тарафыннан, гаризаны теркәгәннән соң җиде эш көне эчендә, җирле үзидарә органы җитәкчесенә җибәрелә.

10. Гаризаны һәм дәлилләнгән бәяләмәне карау нәтиҗәләре буенча җирле үзидарә органы җитәкчесенә түбәндәге карарларның берсен чыгара:

1) муниципаль хезмәткәргә түләүсез нигездә коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга рөхсәт итәргә;

2) муниципаль хезмәткәргә түләүсез нигездә коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга рөхсәт итмәскә;

3) гариза һәм дәлилләнгән бәяләмәне муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссиягә карауга җибәрергә.

11. Әлеге Нигезләмәнең 10 өлешендәге 2 пунктында каралган карар кабул итү өчен нигез булып, муниципаль хезмәткәрнең коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашу очрагында мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү мөмкинлеге тора.

12. Әлеге Нигезләмәнең 10 өлешендәге 3 пунктында каралган карар кабул ителгән очракта, җирле үзидарә органы җитәкчесе тарафыннан әлеге комиссиягә җибәргәннән соң җиде көн эчендә муниципаль хезмәткәрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе гариза һәм дәлилләнгән бәяләмәне карый. Гаризаны һәм

дәлилләнгән бәяләмәне карау нәтиҗәләре буенча муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча комиссия, муниципаль хезмәткәр коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашкан очракта мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү мөмкинлеге булу яки булмау турында карар кабул итә.

13. Әлеге Нигезләмәнең 12 өлешендә каралган карар кабул ителгәннән соң өч эш көне эчендә җирле үзидарә органы җитәкчесе муниципаль хезмәткәргә түләүсез нигездә коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга рөхсәт итү яки рөхсәт итмәү турында карар кабул итә.

14. Карарларның берсе кабул ителгәннән соң өч эш көне эчендә кадрлар эшен алып бару бурычы йөкләнгән зат муниципаль хезмәткәргә кабул ителгән карар турында, гаризаларны теркәү журналында муниципаль хезмәткәрнең имзасын куйдырып, язма рәвештә хәбәр итә яисә яллаучы вәкиле тарафыннан кабул ителгән карар турында, бу хакта хәбәрнамә белән һәм гаризаларны теркәү журналында тамга ясап, почта аша мәгълүмат җибәрә.

15. Гариза, дәлилләнгән бәяләмә һәм гаризаны карауга бәйле башка материаллар (булганда) муниципаль хезмәткәрнең шәхси эшенә теркәлә.

Арча муниципаль районы
муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан
түләүсез нигездә коммерциячел булмаган
оешма белән идарә итүдә
катнашу өчен яллаучы (эш бирүче)
вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе
турындагы Нигезләмәгә 1 нче кушымта

_______________________________________________
(җирле үзидарә органы җитәкчесенең фамилиясе, исеме, вазыйфасы исеме)
________________________________________

_______________________________________________

___________________________________________
(хезмәткәрнең исеме, фамилиясе)
_______________________________________________

_______________________________________________

# ГАРИЗА

түләүсез нигездә коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашуга рөхсәт бирү турында

"Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктының "б" пунктчасы һәм муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы Кодексының 16.1 статьясы нигезендә түләүсез нигездә
коммерцияле булмаган оешма _______________________________________________
(коммерциячел булмаган оешманың исеме,
___________________________________________________________________________
аның урнашу урыны һәм адресы, эшчәнлек төрләре, нинди сыйфатта идарә итү планлаштырыла
___________________________________________________________________________
белән идарә итүдә катнашырга рөхсәт итүегезне сорыйм.

Коммерциячел булмаган оешма белән идарә итү (идарәдә катнашу) хезмәттән буш вакытта башкарыла һәм үз белән мәнфәгатьләр каршылыгына яки биләгән вазыйфаларны башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү мөмкинлегенә китермәячәк.

_______________ _________________________________ "___"___________20___ ел
(имза) (инициаллар, фамилия)

Гаризаларны теркәү журналында
теркәү номеры _____________________________________________
Гаризаны теркәү датасы "___"___________20___ ел

_______________ ________________________________________________________
(имза) (гариза теркәгән затның инициаллары, фамилиясе)

Арча муниципаль районы
муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан
түләүсез нигездә коммерциячел булмаган
оешма белән идарә итүдә
катнашу өчен яллаучы (эш бирүче)
вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе
турындагы Нигезләмәгә 2 нче кушымта

# Түләүсез нигездә коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүгә рөхсәт бирү турында гаризаларны теркәү журналы

| № (гаризаны теркәү номеры) | Гаризаны теркәү датасы | Гаризаның кыскача эчтәлеге | Гариза биргән затның инициаллары, фамилиясе, вазыйфасы атамасы | Гариза кабул иткән затның инициаллары, фамилиясе, вазыйфасы атамасы | Гаризаның күчермәсен алу турында белешмә ("күчермәне алдым", гариза тапшырган затның имзасы) | Вәкаләтле вәкил тарафыннан кабул ителгән карар турында белешмә | Гариза, гариза биргән зат тарафыннан яллаучы вәкиленең карарының күчермәләрен алу турында белешмә ("күчермәне алдым", гариза тапшырган затның имзасы) яисә почта аша яллаучы вәкиленең карарын тапшыру турында хәбәрнамә белән (адрес, имза, карар җибәргән затның имзасы) җибәрү турында белешмә |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 |